**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясепоселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**29.12.2023 ел** **№ 1985**

**«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Биектау муниципаль районы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы карарын гамәлгә ашыру чаралары хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2023 елның 29 ноябрендәге 1530 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетын үтәүгә кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторларына:

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр керүне тәэмин итү, шулай ук аларны түләү бурычларын киметү буенча чаралар күрергә;

салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда каралган түләүләрдән тыш, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетына түләүләр буенча дебитор бурычлары барлыкка килүгә юл куймау һәм күләмнәрен кыскарту буенча чаралар күрергә;

квартал саен «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ тарафыннан билгеләнгән сроклар һәм форма нигезендә керемнәрнең ай саен керү фаразларын тапшырырга;

квартал саен, керемнәр өлешендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында, керемнәр буенча факттагы үтәлешенең фараздан тайпылу сәбәпләрен күрсәтеп, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ билгеләгән срокларда аналитик материаллар тапшырырга;

район бюджеты керемнәренең ведомство буйсынуындагы администраторлары исемлеген билгеләү турында норматив хокукый актлар кабул итүне тәэмин итәргә;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары керемнәренең тиешле бюджет классификациясе кодларына күчерү максаты белән ачыкланмаган керемнәрне оператив рәвештә тәгаенләүне гамәлгә ашырырга;

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет

палатасы» МКУнә Биектау муниципаль районы бюджеты керемнәре чыганаклары реестрын булдыру һәм алып бару өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан раслана торган тәртиптә һәм срокларда кирәкле мәгълүматны тапшыруны тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары вәкаләтләре һәм (яки) алар тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты керемнәре составы үзгәргән очракта, аларга үзгәрешләр кертү турындагы мәгълүматны вәкаләтләргә һәм (яки) идарә ителә торган керемнәр составына үзгәреш кертә торган закон чыгару һәм башка норматив хокукый актлар үз көченә кергән көннән өч эш көне эчендә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУнә кертергә.

3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторы квартал саен «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» МКУ билгеләгән сроклар һәм форма нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты кытлыгын эчке һәм тышкы финанслау чыганаклары чараларын ай саен җәлеп итү һәм каплау фаразларын, элек бирелгән бюджет кредитларын каплау өчен каралган акчаларны кире кайтару суммасын исәпкә алып, тапшырырга тиеш.

4. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының авыл җирлекләренә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУнә җирле бюджетларның үтәлеше турындагы мәгълүматны әлеге карарның 2 пунктының өченче, дүртенче һәм җиденче абзацларында һәм 3 пунктында каралган шундый ук мәгълүматны тапшырырга тәкъдим итәргә.

5.Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

2024 елның 1 гыйнвары хәленә кулланылмаган, максатчан билгеләнешкә ия субвенцияләр, субсидияләр, башка бюджетара трансфертлар рәвешендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан бирелгән бюджетара трансфертларның калган өлеше 2024 елның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетына кире кайтарылырга тиеш;

федераль башкарма хакимият органнарына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр тарафыннан тапшырыла торган бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисаплар «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» МКУ белән килештерелергә тиеш;

6. Әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләренә бирелә торган бюджетара трансфертларның кушымтада бирелгән исемлеген расларга, аларны күчерү буенча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын алучының вәкаләтләрен, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр кабул ителгән карарлары нигезендә 2024 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы буенча Федераль казначылык идарәсенә тапшыралар.

7. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының тармак бүлеге тарафыннан:

2024 елның 1 февраленә кадәр билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына, чыгымнар буенча 2024 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетын үтәүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының норматив хокукый актлары проектларын кертергә.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының муниципаль программаларын «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты турында» 2023 елның 13 декабрендәге 359 номерлы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы карарына бюджет законнарында билгеләнгән срокларда туры китерүне тәэмин итәргә.

8. Биектау муниципаль районының муниципаль заказчыларына, шул исәптән Биектау муниципаль районының муниципаль казна учреждениеләренә 2024 елның 15 гыйнварына кадәр «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУсенә район исеменнән товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә төзелгән муниципаль контрактлар өчен 2023 елда күрсәтелгән муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә каралган файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре калдыклары буенча мәгълүмат бирергә.

9. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләренә файдаланылмаган отпуск өчен акчалата компенсация 2024 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль хакимиятенең тиешле органнарын, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының муниципаль казна учреждениеләрен тотуга бюджет сметаларында хезмәт өчен түләүгә каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә башкарыла;

торгларда катнашучылар тарафыннан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру конкурсында, аукционында катнашуга заявкаларны тәэмин итү буларак кертелә торган акча суммалары, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алуларда катнашучылар тарафыннан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы исеменнән төзелгән муниципаль контрактлары үтәлешен тәэмин итү буларак кертелә торган акча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы учреждениеләре тарафыннан вакытлыча эш итүгә кергән акча белән операцияләрне исәпкә алу өчен аларның Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Биектау районы буенча Казначылык департаменты территориаль бүлекчәсендә үзләре ачкан шәхси счетларында исәпкә алына;

Биектау муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән түләнергә тиешле товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә шартнамәләр (муниципаль контрактлар) төзегәндә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын алучылар әлеге пунктның бишенче-сигезенче абзацларында билгеләнгән күләмдә һәм тәртиптә, әмма тиешле финанс елына аларга кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларыннан артмаган күләмдә һәм тәртиптә түбәндәге тиешле максатларга билгеләнгән тәртиптә аванс түләүләрен күздә

тотарга хокуклы:

а) шартнамә (контракт) суммасының 100 процентына кадәр – басма матбугатка язылу һәм аларны сатып алу турындагы, элемтә, кабель һәм спутник телевидениесе хезмәтләре күрсәтү турындагы шартнамәләр (контрактлары) буенча, ягулык-майлау материаллары, транспорт чаралары, юлламалар, авиация, тимер юл, шәһәр һәм шәһәр яны транспортында йөрү өчен билетлар, ашыгыч кирәкле медикаментлар (кеше тормышына куркыныч янаган хәлләрдә кичектергесез медицина ярдәме күрсәтү өчен таләп ителә торган медикаментлар) сатып алуга шартнамәләр (контрактлары) буенча, квалификация күтәрү курсларында белем алу турындагы, яңадан һөнәри әзерлек узу турындагы, фәнни, методик, фәнни-гамәли һәм башка конференцияләрдә катнашу турындагы, проект документациясенә һәм инженерлык тикшеренүләренә дәүләт экспертизасын үткәрү турындагы, капиталь төзелеш объектларының смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү, аларны реконструкцияләү яки техник җиһазландыру турындагы шартнамәләр, транспорт чаралары хуҗаларының граждан җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү шартнамәләре буенча, мәгълүмат белән тәэмин итү, пассажирлар йөртү һәм багажлар ташу буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү турындагы шартнамәләр буенча, янгын сүндерү чараларын үткәрү турындагы шартнамәләр (контрактлары) буенча, фәнни, мәдәни, экскурсия һәм спорт чараларын уздыруга шартнамәләр буенча;

шартнамә (муниципаль контракт) суммасының 90 процентына кадәр күләмдә – «2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына федераль бюджет турында» Федераль закон нигезендә аларның финанс тәэминатына бирелгән акчалар казначылык озатылырга тиешле шартнамәләр (муниципаль контрактлар) буенча;

шартнамә (муниципаль контракт) суммасының 50 процентыннан артмаган күләмдә – әгәр дә башкасы Россия Федерациясе законнарында каралмаган булса, калган шартнамәләр (контрактлар) буенча.

юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш), индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү 2024 елда Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезләмәләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

10. «Биектау муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МКУнә:

2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетының җыелма бюджет язмасында билгеләнгән күләмдә бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары турында бюджет акчаларының баш бүлүчеләренә хәбәрнамәләр җиткерергә;

2024 елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетына, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы исеменнән товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә төзелгән муниципаль контрактлары шартлары нигезендә 2023 елда түләнергә тиешле әлеге муниципаль контрактларына түләү өчен файдаланылмаган, 2024 елда әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләренең калган өлеше суммасы чикләрендә бюджет ассигнованиеләре күләмнәре турында тәкъдимнәр кертергә;

муниципаль берәмлекләргә муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар сатып алу, эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү белән бәйле субсидияләрне, муниципаль

ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр башкару һәм хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән контракт (шартнамә) булганда күчерүне гамәлгә ашырырга:

шартнамәдә (муниципаль контрактта) билгеләнгән күләмдә аванс өчен түләүгә;

эшләр башкаруны, хезмәтләр күрсәтүне, товар китерүне раслый торган документлар булганда шартнамә (муниципаль контракт) буенча башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр, куелган товар өчен түләүгә.

11. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләргә:

аларга кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм җыелма бюджет язмасының расланган күрсәткечләре нигезендә бюджет йөкләмәләре лимитларын ведомство буйсынуындагы бүлүчеләр һәм (яисә) Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын алучылар арасында бүләргә;

максатчан билгеләнешкә ия булган бюджетара трансфертлар бирелгәндә, авыл җирлекләренә бюджетлар арасында исәпләүләр буенча хәбәрнамәләр җиткерергә.

12. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин

Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 29 декабре № 1985нче карары белән расланды

Максатчан билгеләнешкә ия булган субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләренә бирелә торган, 2024 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты акчасын алучының бюджетара трансфертларны күчерү вәкаләтләре Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджет акчасын баш бүлүчеләр тарафыннан алар кабул иткән карарлар нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы буенча Федераль казначылык идарәсенә тапшырыла торган бюджетара трансфертлар исемлеге

| Бюджетара трансферт исеме | Бюджет акчаларын баш бүлүче исеме |
|---|---|
| Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыруга бюджетларга субвенцияләр | «Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ |
| Авыл территорияләрен төзекләндерү чараларын гамәлгә ашыруга бюджетларга субсидияләр | «Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ |